**СОВЕТ ТАТАРСКО-ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422634, с. Татарский Янтык
ул. Магазинная, дом 31а
тел: 3-26-21

422634, Татар Янтыгы авылы, Кибет урамы, 31а йорт
тел: 3-26-21

---

2023елның «27» апреле                                        51 номер

# КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 34 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатыннан, Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге советы карар кылды:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 34 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2) Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы
авыл җирлеге Советы рәисе                                        Н.Ш.Мифтахов

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының
Татар Янтыгы авыл җирлеге Советының 2023 елның «27» апрелендәге
51 номерлы карарына кушымта

«Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 34 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү.»

1) **1) 2.2 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) тарафыннан вәкаләтләнгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001%;".